# КАРАР

**5 декабрь, 2024 ел №1**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Нырья авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 05 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Нырья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Нырья авылының Комсомол урамындагы юлны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сууткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Нырья авылына янгын гидрантлары өчен будка сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне

гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 170 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 88 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 88 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Нырья авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Нырья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нырья авылының Комсомол урамында юлларны рәтләү, ремонтлау һәм вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, дренаж системасы ясау, суүткәргеч торбалар салу, эш өчен шартнамә буенча түләү, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Нырья авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су

саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү - халыкның күпләп ял итү урыннарын, парклар, скверлар, спорт һәм уен мәйданчыклары, халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл клубын карап тоту, төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, Нырья дигән язма сатып алу һәм урнаштыру), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү, Нырья авылы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары өчен будканы тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Нырья авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, яктырткычлар һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырья авыл җирлеге башлыгы В.И. Павлов